| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.06.2015 г.Казань № 134/2-пр

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 - 2017 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын раслау турында” 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Россельхозбанк” ААҖнең Татарстан төбәк филиалында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында кадрлар үзгәреше булу сәбәпле һәм “Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһере булу мәҗбүрилеген бетерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 6 апрелендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 - 2017 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын раслау турында” 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Крестьян (фермер) хуҗалыкларын (алга таба – КФХ) үстерүгә грантлар бирү һәм эш башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм күрсәтү очен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча Экспертлар советы составыннан Р.В. Гыйләҗевны һәм Ф.Г. Гобәйдуллинаны чыгарырга;

Экспертлар советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Галимҗанов Алмаз Илдус улын - Татарстан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аудит һәм коррупциягә каршы эшчәнлек бүлегенең әйдәүче консультантын;

Вавилова Марина Александровнаны - Татарстан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-толек министрлыгының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегенең әйдәүче киңәшчесен.

1.2. КФХ үстерүгә грантлар бирү һәм эш башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм күрсәтү өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча Ведомствоара конкурс комиссиясе составыннан И.Ф. Фәткулловны, А.Н. Молокинны, Ф.Г. Гобәйдуллинаны, В.Я. Муллиннаны, Р.Р. Кашапованы чыгарырга;

Ведомствоара конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

Нәбиуллина Гөлсинә Натфулла кызын - Татарстан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгечен - Ведомствоара конкурс комиссиясе секретаре итеп;

Гыйләҗев Расил Васил улын - Татарстан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аудит һәм коррупциягә каршы эшчәнлек бүлеге башлыгын;

Низаметдинов Марат Мингали улын - Татарстан Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге башлыгын;

Григорьев Алексей Евгеньевичны - “Россельхозбанк” ААҖнең Татарстан төбәк филиалы директоры урынбасарын;

Парфенова Лариса Александровнаны – “Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге” дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе урынбасарын.

1.3. Боерыкка 2 нче кушымтада:

“Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге” III бүлегенең 3.3. пунктындагы 1 абзацта “ һәм КФХ башлыгы мөһере белән расланырга тиеш” сүзләреннән соң “(мөһер булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

“Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге” III бүлегенең 3.3. пунктындагы 3 абзацта “Мөһер белән беркетелгән һәм КФХ башлыгы имзасы белән расланган” сүзләреннән соң “(мөһер булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

“Гаризаларны кабул итү һәм карау” IV бүлегенең 4.3. пунктындагы 3 абзацта “һәм КФХ мөһере белән раслана” сүзләреннән соң “(мөһер булган очракта)” сүзләрен остәргә.

1.4. Боерык белән расланган Нигезләмәгә 8 нче кушымтаның “Якларның реквизитлары һәм имзалары” 8 бүлегендә “р/с 40201810900000000002 в ГРКЦ НБ” сүзләрен “р/с 40201810900000000002 Казан шәһәренең Татарстан Республикасы НБ-бүлекчәсендә” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөклим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов